КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 31 март г.Казань № 330

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 29 май, 340 нчы, 2009 ел, 2 февраль, 56 нчы, 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2010 ел, 30 декабрь, 1156 нчы, 2011 ел, 4 ноябрь, 918 нче, 2013 ел, 30 сентябрь, 696 нчы, 2013 ел, 16 декабрь, 995 нче, 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче, 2014 ел, 31 гыйнвар, 52 нче, 2015 ел, 26 февраль, 116 нчы, 2016 ел, 19 май, 323 нче, 2016 ел, 3 сентябрь, 613 нче, 2018 ел, 14 апрель, 245 нче, 2019 ел, 7 май, 383 нче, 2019 ел, 12 сентябрь, 821 нче, 2021 ел, 31 май, 396 нчы, 2021 ел, 29 октябрь, 1020 нче, 2022 ел, 22 февраль, 155 нче, 2022 ел, 7 июнь, 533 нче, 2022 ел, 20 июль, 701 нче, 2022 ел, 5 октябрь, 1069 нчы, 2023 ел, 26 гыйнвар, 48 нче, 2023 ел, 17 март, 266 нчы, 2023 ел, 19 июль, 864 нче, 2024 ел, 26 июнь, 469 нчы, 2024 ел, 13 ноябрь, 993 нче, 2024 ел, 30 декабрь, 1260 нчы, 2025 ел, 26 февраль, 116 нчы, 2025 ел, 3 июнь, 407 нче, 2026 ел, 9 гыйнвар, 2 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктның илле алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның мобилизацион әзерлеген һәм мобилизациясен оештыра һәм тәэмин итә»;

4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлыкның хокуклары

4.1. Министрлык түбәндәге хокукларга ия:

4.1.1. Билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләр өчен кирәкле белешмәләр соратырга һәм алырга:

Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзү;

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразын исәпләү;

Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында хисап төзү;

Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының үтәлеше турында хисап төзү;

Министрлык компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү;

4.1.2. Максатчан бюджет һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары, аларның бюджетлары проектлары, күрсәтелгән фондларның расланган бюджетлары буенча материалларны һәм аларның үтәлеше турында хисапларны билгеләнгән тәртиптә соратырга һәм алырга;

4.1.3. Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләргә, бүлүчеләргә һәм алучыларга, кредит оешмаларына Татарстан Республикасы бюджет законнарын ачыкланган бозуларны бетерү, аларны бетерүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру таләбе белән тәкъдимнәр җибәрергә;

4.1.4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджет акчаларын баш бүлүчеләрнең, бүлүчеләрнең һәм алучыларның шәхси счетлары буенча операцияләрне туктатырга;

4.1.5. Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләрнең, бүлүчеләрнең һәм алучыларның шәхси счетларыннан максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган бюджет акчалары күләмендә бюджет акчаларын алырга;

4.1.6. Бюджет акчаларын алучыларның барлык счетларыннан кире кайтару срогы тәмамланган бюджет кредитлары рәвешендә бирелгән бюджет акчаларын, шулай ук бюджет кредитларыннан файдаланган өчен түләнергә тиешле процентларны алырга;

4.1.7. Салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә салымнар һәм җыемнар түләү срокларын үзгәртү турындагы карарны килештерергә;

4.1.8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, ведомство бүләкләрен гамәлгә куярга, алар белән бүләкләү турында карар кабул итәргә.»;

5.3 пунктта:

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацта «һәм аңа буйсынган оешмалар» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин